# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Митинглар, урам йөрешләре, демонстрацияләр һәм пикетлар оештыру һәм уздыру тәртибе турында**

<u>1 статья.</u> Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

митинг - иҗтимагый-сәяси тормыш вакыйгаларына затларның һәм оешмаларның гамәл кылуларына (гамәл кылмауларына) карата гавами мөнәсәбәтләрен белдерү өчен гражданнарның массакүләм җыелуы;

урам йөрешләре - нинди дә булса проблемаларга игътибарны җәлеп итү максатында кешеләрнең билгеле бер маршрут буенча оештырылган массакүләм хәрәкәте;

демонстрация - кешеләр төркеменең, урам йөрешләре вакытында плакатлардан, транспарантлардан һәм күргәзмә үгетләүнең бүтән төрле чараларыннан файдаланып, иҗтимагый-сәяси фикерләрен гавами белдерүләре;

пикетлау - гражданнарны пикетланучы объект янында урнаштыру һәм плакатлар, транспарантлар, күрсәтмә үгетләүнең бүтән төрле чараларын куллану юлы белән урам буйлап йөрмичә һәм тавыш көчәйткечләр кулланмыйча күмәк яисә индивидуаль фикерне гражданнарның гавами белдерү рәвеше;

массакүләм гамәл - гражданнарның оешкан эшчәнлеге, бу эшчәнлек митинг, урам йөрешләре, демонстрацияләр яисә пикетлар рәвешендә аерым таләпләр куюда чагылырга мөмкин;

массакүләм гамәлдә катнашучылар - гамәл оештыруда һәм уздыруда турыдан-туры катнашучы гражданнар;

массакүләм гамәл оештыручылар - иҗтимагый берләшмәләрнең, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең яисә оешмаларның хезмәт коллективлары, шулай ук гражданнарның аерым төркемнәре вәкаләт биргән, унсигез яше тулган затлар. Суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез дип танылган гражданнар массакүләм гамәлләрне оештыручылар була алмыйлар

2 статья. Митинг, урам йөрешләре, демонстрация яисә пикет уздыру турында массакүләм гамәлне оештыручылар аны уздыру билгеләнгән көнгә кадәр ун көннән дә соңга калмыйча җирле администрациягә язмача гариза бирәләр.

Массакүләм гамәлне уздыру турындагы гариза шәһәр (район) администрациясенә яисә, массакүләм гамәлне уздыру район буйсынуындагы шәһәрдә яисә авылда каралса, җирле үзидарә органына бирелә.

3 статья. Гаризада аны бирү көне, гамәлне уздыру максаты, рәвеше, урыны, хәрәкәт итү маршрутлары, аның башлану һәм тәмамлану вакыты, катнашучыларның күздә тотылган саны, гамәлне оештыручыларнын фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, аларның яшәү һәм эшләү (уку) урыны, шулай ук оештыручыларның массакүләм гамәлләр уздырганда җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү буенча оештыручыларнын бурычлары күрсәтелә.

4 статья. Җирле администрация яисә җирле үзидарә органы гаризаны карый, кабул ителгән карар турында аны уздыруга кадәр биш көннән дә соңга калмыйча массакүләм гамәлне оештыручыларга язма рәвештә хәбәр итә.

Җәмәгать тәртибен, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның һәм транспортның нормаль эшен тәэмин итү максатында, шулай ук рәвеше, урыны, вакыты буенча, ләкин максатлары буенча түгел, бүтән массакүләм гамәлләр белән туры килгәндә (бу хакта гариза билгеләнгән вакытлардан иртәрәк яисә бер үк вакытта бирелгәндә һәм үткәрүгә иртәрәк рөхсәт алынганда), җирле администрация яисә җирле үзидарә органы, массакүләм гамәлләрне оештыручылар белән килешеп, массакүләм гамәлләрне уздыруның вакытын һәм (яисә) урынын (маршрутын) үзгәртергә хокуклы.

Җирле администрация яисә җирле үзидарә органы түбәндәге очракларда массакүләм гамәлләр уздыруны тыя:

Кеше хокукларының гомуми декларациясе принципларына каршы килгәндә;

массакүләм гамәлләрне уздыру турындагы гаризада оештыручыларның җәмәгать тәртибе үтәлешен тәэмин итү йөкләмәләре булмаганда, шулай ук әгәр алар элек уздырылган массакүләм гамәлләр буенча алынган йөкләмәләрен берничә тапкыр үтәмәгәндә;

рәвеше, урыны, вакыты буенча, ләкин максатлары буенча түгел, бүтән массакүләм гамәлләр белән туры килгәндә (бу хакта гариза билгеләнгән вакытлардан иртәрәк яисә бер үк вакытта бирелгәндә), оештыручылар массакүләм гамәлне уздыру вакытын һәм (яисә) урынын үзгәртергә риза булмаганда;

предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның нормаль эшчәнлегенә реаль куркыныч туганда;

пассажир һәм тимер юл транспорты хәрәкәтенең маршрутын үзгәртү мөмкин булмаганлыктан, аларның эшен туктатып тору кирәклеге туганда.

Җирле администрация һәм җирле үзидарә органы карарына суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

5 статья. Митинглар, урам йөрешләре, демонстрацияләр һәм пикетлар, гаризада күрсәтелгән максатларга туры китереп, шулай ук мәгълүм вакытларда һәм билгеләнгән урында уздырыла.

Митинглар, урам йөрешләре, демонстрацияләр яисә пикетлар уздырганда массакүләм гамәлне оештыручылар һәм анда катнашучылар башка затларның хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итәргә тиеш. Конституциячел корылышны көч кулланып үзгәртү, социаль, раса, милләтара һәм динара ызгышлар тудыру, көч куллануны һәм сугышны пропагандалау өчен гамәлләр үткәрү хокукыннан файдалану тыела.

Массакүләм гамәлдә катнашучыларга үзләре белән корал, шулай ук кешеләрнең гомеренә һәм сәламәтлегенә каршы кулланылырлык махсус әзерләнгән яисә җайлаштырылган предметлар йөртү тыела.

Дәүләт хакимиятенең һәм идарәсенең республика һәм җирле органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, урындагы затлар, шулай ук гражданнар билгеләнгән тәртипне саклаган хәлдә уздырыла торган митингларга, урам йөрешләренә, демонстрацияләргә һәм пикетларга тоткарлык ясарга хокуклы түгел.

Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының, җирле үзидарә органнарының, иҗтимагый берләшмәләрнең урындагы затларының митинг, урам йөрешләре, демонстрация яисә пикет уздыру хокукларын кысрыклый торган хокукка каршы эш кылуларына карата суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

<u>6 статья.</u> Массакүләм гамәл аны үткәрүгә рөхсәт биргән органның, эчке эшләр органнарының вәкаләтле вәкиле таләбе буенча түбәндәге очракларда туктатыла:

- аны уздыру турында гариза бирелмәгән булса;
- аны тыю турында карар кабул ителсә;
- аны оештыру тәртибе бозылса;
- аны уздыру тәртибе бозылса;
- гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч туса;
- җәмәгать тәртибе бозылса.

<u>7 статья.</u> Эчке эшләр органнары митинглар, урам йөрешләре, демонстрацияләр яисә пикетлар уздырганда җәмәгать тәртибен саклау,

194

хокукка каршы эш кылуларны кисәтү һәм булдырмый калу, гаепле затларны законнар нигезендә җавапка тартуны тәэмин итү чараларын күрәләр.

8 статья. Митинглар, урам йөрешләре, демонстрацияләр һәм пикетлар оештыруның һәм уздыруның билгеләнгән тәртибен бозган затлар законнар нигезендә җаваплы булалар.

Массакүләм гамәл уздырганда анда катнашучылар тарафыннан дәүләткә, иҗтимагый берләшмәләргә, оешмаларга яисә гражданнарга китерелгән матди зыян законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелергә тиеш.

9 статья. Массакүләм гамәлләрне хәвефле яисә зарарлы производстволарга һәм объектларга, тимер юл һәм автотранспорт узелларына якын территорияләрдә, күперләрдә, тимер юлларның, нефть-газ һәм продукт үткәргечләрнең, югары вольтлы электр үткәргечләрнең линияләре тирәсендәге аерылып алынган полосада, гыйбадәт кылу урыннарында, зиратлар һәм гыйбадәт кылу корылмалары территорияләрендә уздыру тыела. Суд бина元лары яисә судларының күчмә утырышларын үткәрү урыннары, алдан ябып тоту, ирекдән мәхрүм итү һәм мәҗбүри дәвалау урыннары янында массакүләм гамәлләр уздыру тыела.

Массакүләм гамәлләрне уздыру өчен чикләнгән урыннарга шәһәрнең төп магистральләре, республика әһәмиятендәге шосселар, кешеләрнең күпләп ял итү зоналары, авыл хуҗалыгы җирләре керә. Массакүләм гамәлләр уздыру чикләнгән була дигәндә, билгеле бер төр гамәлләр уздыруны тыю яки билгеле бер сәгатьләрдә һәм вакытларда (сезоннарда) йә тегесен дә, монысын да бер үк вакытта уздыруны тыю аңлашыла.

Массакүләм гамәлләрне уздыру тыела торган урыннарның һәм массакүләм гамәлләрне үткәрү чикләнгән территорияләрдәге урыннарның исемлеген, анык чикләүләрне күрсәтеп, әлеге статьяның беренче һәм икенче өлешләре нигезендә шәһәрләр (районнар) администрацияләре, җирле үзидарә органнары билгели.

195

10 статья. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты әлеге Закон рәсми басылып чыкканнан соң өч ай эчендә:

- үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга яраклаштырырга;

- әлеге Законнан килеп чыга торган тиешле норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

Әлеге Законны үз көченә кертүгә бәйле рәвештә «Казан шәһәрендә җыелышлар, митинглар, урам йөрешләре, демонстрацияләр һәм пикетлар уздыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының 1991 елның 26 июнендәге 1106-ХП номерлы карары, соңыннан кертелгән үзгәрешләре белән, үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2000 елның 26 апреле
№ 136